**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы**
**Көек Ерыкса авыл җирлеге муниципаль берәмлеге гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

«21» ноябрь 2019 г. № 7

**«Мамадыш муниципаль районы**
**Көек Ерыкса авыл җирлеге составына керүче**
**Малмыжка авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә принциплары турында»гы 6 октябрь, 2003 ел, 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 28 июль, 2004 ел, 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 ст., Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлегенең Малмыжка авылында 2019 елның 21 нояберендә узган үзара салым акчаларын куллану һәм кертү буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлегенең Малмыжка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 нче, 2 нче группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;
-Малмыжка торак пунктында Киров урамындагы су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (иске су торбаларын алмаштыру).

« ӘЙЕ» «ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 96 кеше кертелгән;
халык җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 57 кеше;

Халык җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» 57 кеше тавыш бирде;
«Юк» 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлегенең Малмыжка авылында узган халык җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлегенең Малмыжка авылында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлегенең Малмыжка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 нче, 2нче группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;
-Малмыжка торак пунктында Киров урамындагы су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (иске су торбаларын алмаштыру).

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Көек Ерыкса авыл җирлеге
Советы рәисе

_____________ Ф.Р.Шәйхетдинов
(имза) (имзаның расшифровкасы)